**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка,
423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы,
423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 26 27 декабрь 2022 ел

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**«2023 елга Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында»**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы һәм 9 статьясындагы 11.3 өлеше һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне раслау турында" 1680 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Югары Кәминкә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Минһаҗев М.Н.